**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 22 май № 294

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантлары күләме турында» 2017 ел, 3 февраль, 60 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президентының «2017 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантларын бирү турында» 2017 ел, 1 февраль, ПУ-90 нчы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантлары күләме турында» 2017 ел, 3 февраль, 60 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

бишенче абзацта «4 240,0» саннарын «9 601,8» саннарына алмаштырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенә «Музыка һәм сүз сәнгате аша балалар аудиториясен һәм өлкән аудиторияне җәлеп итү һәм тәрбияләүнең уңай дөньякүләм тәҗрибәсе буларак концертларның филармония абонемент системасын эшләү, үстерү һәм пропагандалау» проекты өчен – 8 798,0 мең сум, «Музыкаль мәдәниятләр һәм дөнья халыклары традицияләре синтезы буларак джаз» проекты өчен – 8 400,0 мең сум, «Россия һәм дөнья халыклары музыкаль мәдәниятенә сәхнә аша татар музыкаль фольклорын тикшерү, пропагандалау һәм интеграцияләү» проекты өчен – 6 700,0 мең сум, «Халыкныкы – халыкка: күренекле россия һәм дөньякүләм вокаль, инструменталь башкаручыларны, коллективларны җәлеп итү аша халык һәм дөньякүләм классик сәнгать шедеврларын саклау, популярлаштыру һәм пропагандалау; гастроль турлары оештыру; конкурслар, фестивальләрдә катнашу, үткәрү; стимуллаштыру, коллективның матди-техник базасын яңарту һәм ныгыту» проекты өчен – 4 634,4 мең сум;»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карар нигезендә грантларны түләү чыгымнары «2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына Татарстан Республикасы бюджет турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында күрсәтелгән максатларга «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы» ведомствосы буенча каралган акча исәбеннән башкарыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\294.docx